# ПАУЛДАН ФИЛИМУНГА ХАТ

*Коллык һәм туганлык*

1-2 Кадерле дустыбыз һәм хезмәттәшебез Филимунга, шулай
ук синең йортыңа җыелучы иман итүчеләр бердәмлегенә, туга-
ныбыз Апфия ханым һәм көрәштәшебез Архипка Мәсих Гайсә
хакына төрмәдә утыручы Паул һәм имандашыгыз Тимутедән
сәлам. 3 Атабыз Аллаһы вә Раббы Гайсә Мәсихтән сезгә мәрхә-
мәт һәм иминлек булсын.

4 Туганым Филимун, догаларымда сине искә төшергәндә,
һәрвакыт Аллаһыма рәхмәт укыйм, 5 чөнки Раббы Гайсәгә
иманың һәм изгеләргә карата мәхәббәтең турында еш ишетәм.
6 Иманыңны башкалар белән дә нәтиҗәле итеп бүлеш һәм, без
Мәсихтә ия булган бар игелекне алар тулысынча аңласын дип,
дога кылам. 7 Туганым, мәхәббәтең миңа олы шатлык һәм зур
юаныч булды, чөнки синең аша иман итүчеләрнең күңелләре
сафланды.

8 Мәсихтә рухи кардәшең буларак бурычыңны үтәүне таләп
итәргә хакым булса да, 9 башка һичкем түгел, мин, Паул –
Мәсих Гайсәнең илчесе һәм дә Аңа иман итүем* өчен хәзер
төрмәдә утыручы тоткын – сиңа мәхәббәткә таянып мөрәҗә-
гать итүне кулайрак күрәм. 10 Үземнең улым Онисим** хакына
сиңа мөрәҗәгать итәм, чөнки зинданда мин аның рухи атасы
булдым. 11 Элек ул сиңа файдасыз иде, хәзер исә синең өчен дә,
минем өчен дә файдалы.

12 Аны, йөрәгемнән өзеп, кире синең янга җибәрәм. 13 Мин
аны үз янымда калдырырга теләр идем: ул сине алыштырып,
Яхшы хәбәр хакына зинданда вакытта миңа ярдәм итәр иде.
14 Әмма бернәрсәне дә синең ризалыктан башка эшлисем кил-
мәде. Ул вакытта игелекле эшең үз теләгең буенча түгел, бәлки

---

* 1:9 *Мәсих Гайсәнең илчесе һәм дә Аңа иман итүем* – Бу сүзләрне грек теленнән болай да аңларга мөмкин: «инде карт кеше һәм дә Мәсих Гайсәгә иман итүем».

** 1:10 *Онисим* – Бу грек исеме «файдалы» дигәнне аңлата.

ирексезләп кушканга булыр иде. [15] Ул синең янда бөтенләйгә
калсын өчен, синнән вакытлыча аерылып торган булуы да их-
тимал. [16] Аны хәзер кол кебек түгел, бәлки колга караганда
яхшырак итеп, якын туганың кебек каршы ал. Мин аны бик
яратам, әмма, синең өчен, кеше буларак та, мәсихче буларак та
ул тагын да кадерлерәк булыр.

[17] Шулай булгач, әгәр мине имандаш күрсәң, аңа да, мине
кабул иткәндәй, ачык чырай күрсәт. [18] Ул сиңа нindидер зыян
китергән икән яки бирәчәге булса, боларны минем бурычым
итеп сана. [19] Мин, Паул, моны үз кулым белән язам: сиңа үзем
түләрмен; инде үзеңнең дә тормышың белән миңа бурычлы бу-
луыңны әйтеп тормыйм. [20] Әйе, туганым, Раббы хакына миңа
яхшылык кыл; Мәсихтә имандаш буларак, күңелемне күтәр.
[21] Бу үтенечемне кире какмасыңа ышанып язам һәм, сораганы-
ма караганда, синең күбрәк тә эшләячәгеңне беләм.

[22] Шулай ук минем өчен дә бер бүлмә хәстәрләп куйчы, чөн-
ки догаларыгызга җавап булып сезгә кире әйләнеп кайтырмын
дип өметләнәм.

[23-24] Мәсих Гайсә хакына кулга алынган Эпафрас һәм хез-
мәттәшләрем Марк, Аристарх, Димас һәм Лүк шулай ук сине
сәламли.

[25] Раббы Гайсә Мәсихнең мәрхәмәте сезнең рухыгыз белән
булсын.